| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 19 сентябрь 2014 ел | Казан шәһәре | № 10-25/кс |

***МУП “Чирмешән районы коммуналь челтәре” тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын күмү һәм үтилләштерү хезмәте өчен тарифларны билгеләү турында***

“Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында” 30.12.2004 № 210-ФЗ Федераль кануны нигезендә, “Коммуналь комплекс оешмаларының эшчәнлек өлкәсенә караган чик индекслар, өстәмәләр, тарифларны җайга салу һәм бәяләрне билгеләү нигезләре турында” 14.07.2008 № 520 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, 15.06.2010 №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. МУП “Чирмешән районы коммуналь челтәре” тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын күмү һәм үтилләштерү өлкәсендә күрсәткән хезмәте өчен тарифларны, әлеге карарның 1нче кушымтасын исәпкә алып, календарь бүленеше нигезендә билгеләргә.

2. Түбәндәге карарның 1нче пунктында билгеләнгән тарифлар 2014 елның 01 нояберennән 2017 елның 31 декаберенә хәтле үз көченә ия була.

3. Каты көнкүреш калдыкларын күмү һәм үтилләштерү өлкәсендә хезмәт күрсәткән коммуналь комплекс оешмаларының җитештерү программаларының төп күрсәткечләрен, 2нче кушымтага таянып һәм әлеге карарның 2нче пунктында күрсәтелгән тарифларның гамәлдә булу чорына килештерергә.

4. Россия Федерациясе Хөкүмәте 30.12.2009 № 1140 карары белән расланган, иректе кулланышка кертелергә тиешле информацияне ачу стандартларына нигезләнеп, “Чирмешән районы коммуналь челтәре” МУПнә алдагы җайга салу чорына тарифларны билгеләү турында нәтиҗәгә килгәч, 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле информацияне ачырга.

5. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәте күрсәтүгә бу карарда билгеләнгән тариф “Коммуналь комплекс оешмалары товарларының һәм хезмәтләр күрсәтүләренең кулланучылар өчен куллану мөмкинлеге критерийлары системасын билгеләү турында” 24.02.2014 № 56 Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты боерыгы белән расланган

коммуналь комплекс оешмалары товарларының һәм хезмәтләр күрсәтүләренең кулланучылар өчен куллану мөмкинлеге критерийларына туры килә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча дәүләт комитеты карарына
1нче кушымта
19 сентябрь 2014 ел № 10-25/кс

## МУП “Чирмешән районы коммуналь челтәре” тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын күмү һәм үтилләштерү хезмәте өчен календарь бүленеше нигезендә тарифлар

| № п/п | Коммуналь комплексы оешмасы, муниципаль берәмлек исеме | Каты көнкүреш калдыкларын күмү һәм үтилләштерү хезмәте өчен тарифлар, сум/куб.м | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 ноябрь 2014 ел - 31 декабрь 2014 ел | 1 гыйнвар 2015 ел - 30 июнь 2015 ел | 1 июль 2015 ел - 31 декабрь 2015 ел | 1 гыйнвар 2016 ел - 30 июнь 2016 ел | 1 июль 2016 ел - 31 декабрь 2016 ел | 1 гыйнвар 2017 ел - 30 июнь 2017 ел | 1 июль 2017 ел - 31 декабрь 2017 ел |
| | Чирмешән муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | МУП «Чирмешән районы коммуналь челтәре»* | 304,03 | 304,03 | 306,47 | 306,47 | 332,29 | 332,29 | 332,29 |

<*> гадиләштерелгән салым алу системысы кулланыла

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештуры һәм җайга салу бүлеге

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча дәүләт комитеты карарына
2нче кушымта
19 сентябрь 2014 ел № 10-25/кс

# Каты көнкүреш калдыкларын үтилләштерү һәм күмү өлкәсендә “Чирмешән районы коммуналь челтәре” МУПнең җитештерү программасының төп күрсәткечләре

| Коммуналь комплексы оешмасының исеме | 01.11.2014 алып 31.12.2014 кадәр | | | | | 01.01.2015 алып - 31.12.2015 кадәр | | | | | 01.01.2016 алып - 31.12.2016 кадәр | | | | | 01.01.2017 алып - 31.12.2017 кадәр | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Коммуналь комплексы оешмалары җитештерү программарарының күрсәткечләре, мең куб.м | | | | Кирәкле тулай керем, мең сум. (ӨБС керми) | Коммуналь комплексы оешмалары җитештерү программарарының күрсәткечләре, мең куб.м | | | | Кирәкле тулай керем мең сум. (ӨБС керми | Коммуналь комплексы оешмалары җитештерү программарарының күрсәткечләре, мең куб.м | | | | Кирәкле тулай керем мең сум. (ӨБС керми | Коммуналь комплексы оешмалары җитештерү программарарының күрсәткечләре, мең куб.м | | | | Кирәкле тулай керем мең сум. (ӨБС керми |
| | Каты көнкүреш калдыкларын үтилләштерү һәм күмү күләме, шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын үтилләштерү һәм күмү күләме, шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын үтилләштерү һәм күмү күләме, шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын үтилләштерү һәм күмү күләме, шул исәптән: | | | | |
| | Барлыгы | Кулланучылар | Бюд-жеттагы кулланучылар | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Кулланучылар | Бюд-жеттагы кулланучылар | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Кулланучылар | Бюд-жеттагы кулланучылар | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Кулланучылар | Бюд-жеттагы кулланучылар | Башка кулланучылар | |
| МУП «Чирмешән районы коммуналь челтәре»* | 8,6 | 4,48 | 1,98 | 2,14 | 2614,67 | 8,75 | 4,63 | 1,98 | 2,14 | 2670,96 | 8,8 | 4,68 | 1,98 | 2,14 | 2810,54 | 8,8 | 4,68 | 1,98 | 2,14 | 2924,14 |

<*> өстәмә бәягә салымны түләүчеләр рәтенә керми

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештуры һәм җайга салу бүлеге